УДК 37.058 DOI: 10.22378/he.2019-4-2.294-311

# КАЗАННЫҢ ИСКЕ ТАТАР БИСТӘСЕ – XIX–XX ЙӨЗ БАШЫНДА ТАТАР МӘГАРИФЕ ҮЗӘГЕ (УКУ ЙОРТЛАРЫНА ТАРИХИ КҮЗӘТҮ)

***Э.К. Сәлахова***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*ilsalah@mail.ru*

Иске Татар бистәсе – Казан шәһәренең татар халкының күпгасырлы тарихын чагылдырган биналары сакланган тарихи үзәге булып тора. Бистәнең оешуы халык тарихындагы драматик вакыйгалар белән бәйле. 1552 елда, Казан ханлыгы яшәүдән туктагач, татар җәмгыятенең тормышы Кабан күле артындагы бистәгә күчә. XVI гасыр ахырына Иске Татар бистәсе Казан шәһәренең мөселман бистәсе рәвешен ала. Беренче мәчетләр, беренче мөселман уку йортлары нәкъ менә шунда ачыла. Иске Татар бистәсе берничә гасыр дәвамында татарларның белем һәм мәдәният үзәге була. Татар бистәсенең рухи тормышын өйрәнү – тикшерүчеләр өчен мөһим бер юнәлеш. Бистә халкы татар милләтенең шәһәр мәдәниятын саклап калу гына түгел, ә аны үстерүгә дә ирешә. Биредә мәчетләр төзелә, мәктәпләр, мәдрәсәләр ачыла, аларны яшәтү өчен матди база да булдырыла.

XIX–XX йөз башында Казан шәһәренең Иске Татар бистәсендә татар мәгарифенең барлыкка килүе һәм үсешен комплекслы рәвештә карау, тикшерү – хезмәтнең яңалыгы булып тора.

Мәкаләнең максаты булып уку йортлары, мәктәп һәм мәдрәсәләрнең барлыкка килү һәм үсеш тарихын өйрәнү, анализлау, татар-мөселман җәмгыятенең рухи тормышында аларның мөһимлеген күрсәтү тора. Максатка ирешү өчен берничә бурыч билгеләнде. Билгеле булганча, татарларда уку йортларының тарихы мәчетләр тарихы белән тыгыз бәйләнештә. Күпчелек мәктәпләр мәчетләр каршында ачылган. Мәдрәсәләр, урта һәм югары баскыч уку йортлары, формаль рәвештә мөстәкыйль уку йортлары булып исәпләнсәләр дә, чынлыкта аларның барлыкка килүе һәм үсеше турыдан-туры дини оешмалар белән бәйле. Уку-укыту процессын тәэмин итүчеләр дә дин әһелләре – имам-хатыйплар булган. Шуңа күрә, безнең фикеребезчә, уку йортларының барлыкка килү тарихы мәчет тарихлары белән тыгыз элемтәдә өйрәнелергә тиеш.

Мәкаләдә Иске Татар бистәсендәге 10 мәхәллә һәм мәчет карала. Автор мәхәллә турында мәгълүмат биргәндә, шул мәхәлләгә караган уку йорты ачылу һәм аның үсеше хакында сөйли. Шулай ук автор бистәдәге уку йортларының кадими укыту методыннан җәдидчәлеккә күчү этапларын да карый. Мәкаләдә Иске Татар бистәсен мәдәни һәм белем ягыннан үзләштерү чорлары да күрсәтелә. Хәзерге вакытта Мәрҗани исемен йөртүче Беренче мәчет бистәдә беренче дини оешма була, аннан соң озак та тормый Апанай мәчете калка.

Мәчетләрнең матди базасы нигезендә Россия империясенең мөселман дөньясының башка уку йортлары белән конкурент була алырлык атаклы уку йортлары ачыла. «Мәрҗани мәдрәсәсе», «Апанай мәдрәсе» («Касыймия») моңа дәлил. Шулай ук мәкаләдә «Мөхәммәдия», «Халидия», «Гаффария», «Үтәмешевләр мәдрәсәсе», «Госмания» һәм башкалар турында киң мәгълүмат бирелә. Кайбер мәдрәсәләрнең исемнәре үзгәргән, бер үк мәдрәсә төрле чорда, төрле чыганакларда төрлечә аталганын әйтеп үтү кирәк. Бу да автор тарафыннан аңлатыла. Автор укыту методлары, заман таләбе белән аларның үзгәрешләрен зур мәдрәсәләр мисалында күрсәтә. Тикшерү материаллары мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту процессын күзаллау, төрле чорда шәкертләр саны динамикасын күрү мөмкинлеген тудыра. Укыту процессын оештыру бар уку йортларында да якынча бер төрле булганга, һәр мәдрәсә турында язу кабатлану булыр иде, шуңа автор башка мөһим фактларга игътибарны юнәлтә. Сакланып калган архив документлары «Касыймия» мәдрәсәсенә рус теле укытуны керткәндәге проблемалар, шәкертләрнең яңа предметны ничек кабул итүләрен күзалларга мөмкинлек бирә. Шундый ук хәл башка мәдрәсәлрдә дә кабатлана.

Мәдрәсә һәм мәктәпләр XX йөз башында татар интеллегенциясенең иң актив вәкилләре булган белемле яшьләрне тәрбияли. Алар күренекле галимнәр, язучылар, педагоглар, мәдәният хезмәткәрләре булып җитешәләр. Автор мәдрәсә турында язганда бу мәдрәсәне тәмамлаган күренекле укучыларының исемнәрен дә атый.

Мәчетләрне, мәдрәсләрне булдыру, аларны матди яктан тәэмин итеп тору татар җәмгыятенең мөлкәтле катламыннан башка мөмкин булмас иде. Сәүдәгәр һәм эшкуарлар Юнысовлар, Арсаевлар, Мостафиннар, Әҗемевләр һәм башка бик күп хәйриячеләр исемнәрен атау татарларда мәгариф үсеше тарихы хакында белемебезне киңәйтә.

Тикшерү архив документларына, шулай ук әлеге тематика буенча булган фәнни әдәбиятка нигезләнә.

**Ачкыч сүзләр:** Иске Татар бистәсе мәчетләре, Иске Татар бистәсендәге уку йортлары, мәчетләр каршындагы мәктәпләр, татарларда мәгариф, татар халкы тарихы, «Касыймия» мәдрәсәсе, Мәрҗани мәчете, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, татар хәйриячеләре.

**Цитата өчен:** Салахова Э.К. Казанның Иске Татар бистәсе – XIX–XX йөз башында татар мәгарифе үзәге (уку йортларына тарихи күзәтү) // Историческая этнология. 2019. Т. 4, № 2. С. 294–311. DOI: 10.22378/he.2019-4-2.294-311

XVI йөзнең беренче яртысында барган сәяси хәлләрнең аяныч нәҗтиҗәсе буларак Казан ханлыгы дәүләт булып яшәүдән туктагач, татар халкының тарихында зур үзгәреш була. Әлбәттә, күп гасырлык мәдәнияткә ия булган халыкның бар мирасы, белеме бер мизгелдә юкка чыга алмый. Тарихны, халыкның казанышларын килеп туган шартларда саклап калу юлларын эзләү мәсьәләсен кую кирәк була. Шулай итеп, татар тарихының дәүләтчелек чорында җыелган белем, мәдәният үзәге аның зыялы катламы белән авылларга күчә, Казан шәһәренең бары кечкенә генә

бер бистәсе – Татар бистәсе – татар рухының, аның мәдәниятын саклап калуның бер урыны була. Алга таба бистә зур Татар дәүләтенең кечерәйтелгән, концентрацияләнгән бер өлешенә әйләнә. Географик яктан караганда, Казан шәһәренең иң начар, сазлыклы җиренә урнашкан, территориясе ягыннан да кечкенә генә булган бу җирдә мәчет салына, тора-бара монда мәчетләр саны ишәя. Татар-мөселманнар өчен мәчет гыйбадәт кылу урыны гына түгел ул. Мәчет – гыйлем, мәдәният, җәмгыять үзәге. Хәзерге вакытта берничә ведомство алып барган эшне элек мәчет, иманнар алып барган. Мәчет тирәсенә оешкан мәхәллә – җәмгыятьнең бер өлеше, татар җәмгыяте – мәхәлләләр җыелмасыннан торган. Һәр мәчет каршында мәктәп эшләгән. Үз остазы булып аерым бина булдыру мөмкинлеге булган очракта, мәдрәсәләр оешкан. Мәдрәсәләре булу, хәтта ки ислам дөньясында танылган уку йортлары булу – халыкның дәрәҗәсен билгели торган күрсәткеч [24]. Мәчет булган җирдә татар һәрвакыт уку йорты – мәктәп яисә мәдрәсә булдырган [27].

Казанга императрица Екатерина II килгәнчегә кадәр Иске Татар бистәсендә бары тик XVIII йөзнең 40 нчы елларында төзелгән бердәнбер агач мәчет була [26, с. 17]. 1767 елның маенда Казанга килгән «әби патша»дан бистә җәмәгатьчелеге бистәдә ике таш мәчет төзүгә рөхсәт сорый. Иске Татар бистәсендә «әби патша» рөхсәтеннән соң салынган беренче мәчет – Беренче Таш мәчет (хәзерге исеме – Мәрҗани мәчете) булса, икенчесе – бу мәчеткә бик якын урнашкан Апанай мәчете. Апанай мәчетен Якуб бине Солтангали үз акчасына төзетә, ә Беренче Таш мәчет төзелешенә бар мәхәллә, Казанның мөлкәтле күп кенә кешесе катнаша. Ш. Мәрҗани мәгълүматы буенча, мәчет төзүгә 62 кешенең хәләл малы керә, алар мәчет төзелешенә биш мең сум акча җыялар. Мәчет өчен имам Әбүбәкер бине Ибраһим, мөәззин Исхак бине Ибраһим, Мортаза бине Йосыф һәм Якуб дигән кеше үзләренең җир кишәрлекләрен хәйрия итәләр. Бирелгән рөхсәттән шартлар үзгәреп киткәнче тиз арада файдаланып калу өчен, мәчет төзелешен тиз тотарга тырышалар, мәчет ашыгычлык белән төзелә. 1771 елга мәчетләр инде төзелеп бетә.

Казан дәүләте мөстәкыйльлеген югалтканнаен соң, Иске Татар бистәсендә барлыкка килгән әүвәлге уку йортлары булып Беренче (Юнысовлар) һәм Апанай мәчете каршындагы уку йортлары санала. Беренче мәчет каршындагы мәдрәсә Казанның өченче гильдияле сәүдәгәре, ахун Ибраһим Хузяш (Әфәнде хәзрәт) тарафыннан 1796 елда төзетелә. Ибраһим Хузяш бу мәчеткә имам булып 1794 елда килә, чыгышы белән Әлмәт ягы кешесе. Гыйлем иясе, заманының атаклы дини уку йортларында белем алган бу кеше Бистә халкы өчен табыш була, ул бу мәдрәсәдә татар-мөселман җәмәгатьчелегенә дин сабагы, ислам фәлсәфәсен аңлатучы зат, аның заманында татарлар арасындагы кайбер гадәтләргә-карашларга да яңача карау бу кеше исеме белән бәйле. Кабан күле буена төзелгән бинаның ике зур бүлмәсе, аш бүлмәсе, ишегалды булган. Бу остазның мәдрәсә ачылган

көннәрдән үк шәкертләре күп булган. 1816 елгы мәгълүмат буенча, монда 50 шәкерт белем алганлыгы билгеле.

Иске Татар бистәсенең икенче мәдрәсәсе икенче гильдияле сәүдәгәр Бикбау Хәлфин тарафыннан 1808 елда төзетелә, 1815 елда янкорма эшләнә. 1808 елдан ук мәдрәсәне гарәп илләрендә, Бохарада 15 ел буе дини белем алган бик гыйлемле Салих бине Сәгыйдь бине Хәсән әл-Кили (1825 елда вафат) җитәкли. Бу мәдрәсә шәкертләр саны ягыннан Беренче мәхәллә мәчете мәдрәсәсеннән дә зуррак булган. 1820 елларда бу мәдрәсәдә 80 шәкерт укыган. Мәдрәсә бинасы ике бүлмә, кухня һәм ишегалдыннан торган [21, кгз. 10–11].

XIX йөзнең 50 нче еллары мәгълүматлары буенча, Казан шәһәрендә дини уку йортларыннан 7 мәдрәсә эшли. Шулардан Иске Татар бистәсеннең икенче өлешендә ике мәдрәсә була. Бу мәдрәсәләр – дәүләт оешмаларыннан мөстәкыйль уку йортлары, беркем каршында да хисап тотмыйлар. Берсендә 47 шәкерт, икенчесендә әлеге елларда 92 шәкерт укуы билгеле. Беренче мәчет каршында эшләгән мәдрәсә Юнысовлар химаясенә көн күрсә, икенчесе тулысы белән шәкертләр, аларның аталары, мәхәллә җәмәгатьчелегеннән җыелган акчага яшәгән.

Иске бистәнең өченче өлешендә ике мәдрәсә эшли: аларның берсе – Казан сәүдәгәре Корбангали Рысаев акчасына 1826 елда ачыла, биредә барлыгы 80 шәкерт укыган, 1832 елда ачылган мәдрәсә Бәшир Аитов акчасына көн күрә, у мәдрәсәдә 110 шәкерт белем эстәгән. Барлык мәдрәсәдә дә бары тик берәр хәлфә эшли.

Яңа Татар бистәсендә Казан сәүдәгәрләре Мөхәммәд Кашаев, Корбангали Рысаев, Корбангали Сабаев акчасына яшәгән мәдрәсәләр эшләп килгән. Укыту предметларына килгәндә, аларның барысында да бер үк төрле белем бирелгән: шәкертләр гарәпчә, фарсыча, төркичә уку-язу кагыйдәләрен өйрәнгәннәр, Хәдис, арифметика укытылган.

Казан шәһәрендә тора-бара мөселман уку йортлары саны арта бара. 1854 елга аларның саны 8 гә җитә [8, кгз. 12], 1891 елда – 10 [13, кгз. 34], 1909 елда – 11 була [14, кгз. 2 б.]. 1913 елда Казан шәһәре буенча 26 мәктәп һәм мәдрәсә булганлыгы билгеле, аларның 20 се кадими уку йортлары була, ә 6 сы инде яңа – «ысулы саутия» методы белән эшли торган яңа карашлы, дөньяви предметлар буенча да белем бирә торган уку йортлары булып җитешәләр. Шуларның – 14 е мәдрәсә, 12 се мәчетләр каршында эшләгән мәктәпләр. Бу вакытта мәдрәсәләрдә 1248 шәкерт белем алган, ә мәктәпләрдә кызлар да белем алган, аларны абыстайлар укыткан. Бу вакытта мәктәпләрдә 96 кыз бала, 561 ир бала укыганнар [3, кгз. 9].

Татар-мөселман уку йортларының матди нигезен аерым кешеләр, аерым химаячеләрнең ярдәме тәшкил иткән. Ике Татар бистәсенең – Яңа һәм Иске бистәләренең күпчелек уку йортларын төзүче һәм тотучы конкрет кешеләр була. Алар, Юнысовлар, Арсаевлар, Мостафиннар, Әҗемевләр [8, кгз. 12]. Мәдрәсәләрнең шул вакыттагы исемнәре дә, нигездә, мәдрәсә төзетүче, аны тотучы кеше исеме белән аталып йөргән. 1854 елга Бистә-

дәге уку йортларының исемнәре: Иске Татар бистәсендә – Апанаевлар (ачылу вакыты – 1826 ел), Аитовлар уку йорты (1832 ел), Юнысовлар (ачылу вакыты – 1836 ел), Якуповлар (1837 ел), Әҗемевләр (1849 ел). Яңа Татар бистәсендә Әҗемевләр исеме белән билгеле булып Юнысовлар акчасына тотылган уку йорты 1817 елда ук ачыла, монда XIX йөз уртасында 20 бала укый, шулай ук Яңа бистәдә Мостафиннар, Арсаевлар уку йортлары булган, анда да ике дистә бала белем алган [8, кгз. 12].

Иске Бистәнең иң атаклы мәдрәсе «Апанай мәдрәсәсе» – Апанай мәчете мәхәлләсенә караган мәдрәсә була, әмма төрле вакытта төрле исем йөртә. Аның «Күлбуе», «Кәримия», «Галләмия», «Касыймия» дигән исемнәре дә билгеле. Бу мәдрәсә турында Җамал Вәлиди, инкыйлабка кадәрге мөселман уку йортлары арасында беренче урынны алып тора, дип яза. Бу мәдрәсә урнашкан икенче мәхәлләдә шул чорның иң атаклы нәсел вәкилләре яши, атаклы мөгаллимнәр дә биредә була [23, 270 с]. Бу мәдрәсәнең укытучы имамнары – Бохарада дини гыйлем алган кешеләр. Бу мәдрәсәнең атаклы мөдәррисләреннән берес – чыгышы белән Казан арты Кенәр авылыннан булган мелла Исхак бине Сәгыйдь бине Колмөхәммәд бине Ишмөхәммәд әл-Кенәри. Ул 1831 елда Казан шәһәренең Икенче мәчет имамы Фәхретдиннең вафатыннан соң килә. Ш. Мәрҗани язуынча, «күл буенда үз йорты янына мәдрәсә төзетеп, бераз вакыт шөһрәт белән дәрес итә» [25, 247 б.]. Мәдрәсәнең атаклы мөдәррисләрнең тагын берсе – мелла Салих бине Сәгыйдь бине әл-Хәсән әл-Кили. Мәрҗани аның турында: «Казанга күчеп, икенче мәчеттә имам вә мөдәррис була. Ул анда зур мәдрәсә тотып, күп шәкертләр җыйнап дәрес укыта һәм дан, шөһрәт казана», дип яза [25, 321 б.]. Ислам дөньясында танылган шәхесләрнең остазы да ул. Аның шәкертләре арасында мелла Габдессаттар ахун, аның энесе мелла Габделгаффар бине Сәгыйдь, мелла Максуд бине Корбангали бине Атнагол әл-Күлбаши, ахун мелла Фәтхулла бине Сәфәр бине Хөсәен әл-Мөнәвези һәм башкалар [25, 322 б.].

Татар җәмгыятендәге яңа сулыш мәдрәсәгә үзгәрешләр кертә, дини предметларны гына өйрәтүче мәдрәсә буларак ачылган «Апанай мәдрәсәсе» чын мәгънәсендә яңа – җәдиди уку йорты булып җитешә. XX йөз башында мәдрәсәне үзе дә шул ук мәдрәсәне тәмамлаган, Апанай мәчете имамы Мөхәммәд Касыйм улы Салихов җитәкли. Мәдрәсәнең башка мөгаллимнәре дә шул мәдрәсәне тәмамлаган шәкертләр була. Башлангыч 4 сыйныф балаларын 1910 елдан башлап 24 яшьлек мөгаллим чыгышы белән Тәтеш өязе Яңасала авылыннан булган Карибулла Вәли улы Сираҗетдинов укыта. 1908 елдан башлап 7 сыйныфка кадәрге шәкертләргә Казан артының Сәләнгеш авылыннан Назыд Харис улы Хафизов белем бирә. «Апанай мәдрәсәсе» укытучыларыннан Казан өязе Сая авылының Габдрахман Сәгъди улы Вәлитов, чыгышы белән Нижгар ягыннан булган Вәлиулла Хәсән улы Юнысов, Мөхәммәдшакир Ибраһим улы Ваһитов, Мөхәммәдбари Һади улы Фазлуллин, Габделкәрим Бәдретдин улы Яхин булалар. Бу уку йорты ике өлештән: мәктәп һәм мәдрәсә (сәнәви

бүлеге) торган. 1913 ел мәгълүматы буенча, мәктәбендә 77 бала белем алса, мәдрәсә өлешендә 120 шәкерт белем эстәгән. Шулай итеп, барлыгы 206 ир бала бушлай белем алу өчен шартлар тудырыла. Бу уку йортының попечителе итеп 1911 елда Шакир Закир улы Апанаев сайлана. Мәктәп һәм мәдрәсәне тоту өчен Юнысов, Апанаев һәм Гариф Үтәмешев тарафыннан хәйрия ителгән сәүдә лавкасы, мәхәллә әгъзалары тарафыннан төзелгән һәм елына 400 сум табыш бирә торган мәчет ишегалдындагы лавка керемнәре тотылган. Шулай ук уку йорты өчен Госманов, Вәли Апанаев, Әхмәд Хөсәенов, Ямашев малларының табышларыннан кергән өлешләр тотылган [6, кгз. 27–28]. Мәдрәсә чыгымы елга 3000 сум тирәсе тәшкил иткән [6, кгз. 27–28].

Мәдрәсәнең беренче чорда төгәл укыту программасы булмый, мөдәррисләр үзләре кулай күргән, үзләре күзаллаган программа белән укыталар. XX йөз башына инде мәдрәсәләргә реформа, үзгәрешләр керә башлагач, «Апанай мәдрәсәсенең» дә үз уку программасы формалаша. 1913/1914 еллардагы уку программасы буенча 12 еллык уку-укыту курсы 3 бүлектән тора: 1) ибтидаи; 2) рөшдия; 3) игъдадия. Һәр бүлекне үтү вакыты 4 ел була. Башлангыч ибтидаи бүлектә дин белеме, татар теле, арифметика, география нигезләре өйрәтелсә, рөшдиядә программа киңәйтелеп, дин гыйлеме, татар теле, гарәп теле, арифметика, тарих, география укытылган. Соңгы игъдадия бүлеге дин гыйлеме, гарәп теле, логика, тарих һәм геометрия буенча белем бирүне башкара [2, кгз. 169–170]. Дөньяви фәннәр мәдрәсәдә дини предметлардан өстенрәк була башлый. Бу мәдрәсә мөгаллимнәре арасынннан татар җәмгыятендә танылган шәхесләр чыгуы да мәдрәсәнең дәрәҗәсен күрсәтә торган билге. Гарәп телен киләчәктә педагог, журналист, нашир булып танылачак Әхмәдһади Максуди укытса, 1909 елдан башлап төрки һәм гарәп әдәбияты дәресләреннән булачак тюрколог Заки Вәлиди белем биргән. Мәдрәсә каршындагы рус классында драматург Гафур Коләхметов эшли, ул арифметика дәресләрен дә алып бара.

«Апанай мәдрәсәсендә» 1873 елда рус класслары ачу аңлашылмаучанлык китереп чыгара. Рус класслары булдыру татар мәдрәсәләрендә җиңел генә кабул ителми, «Апанай мәдрәсәсе» шәкертләре, замандагы үзгәрешләрне күреп, рус телен өйрәнүгә каршы булмасалар да мәдрәсәгә китерелгән рус теле укытучысы Вафа Мусинны кабул итмиләр, укытучы буларак Каюм Насыйри билгеләнә дип вәгъдә бирелгән була [10, кгз. 2.]. Вафа Мусинга каршы торуга татар-башкорт уку йортлары инспекторы В.В. Радловның ачуы чыгып, ул мәдрәсәне яптыру ниятендә була. Әмма конфликт зурга китмичә, Вафа Мусин белән аралашкан, аңа ризасызлыгын белдергән Хәсән Тангатаров һәм Габдерәкыйп Нургалиевны мәдрәсәдән чыгару белән генә тәмамлана.

Инкыйлаб вакыйгалары да мәдрәсәне читләтеп үтми, шәкертләр арасында революцион карашлар тарала. Хәтта ки мәдрәсә укытучысы Габделбари Сәлимовка һөҗүм иткән, революцион җырлар җырлаган шәкертләргә шикаять итүләр да була [18, кгз. 115–116].

Төрле елларда «Апанай мәдрәсәсендә» татар халкының күренекле шәхесләре – язучы, җәмәгать эшлеклесе Г.Г. Исхакый (1878–1954), дин галиме М.Я. Бигиев (1873–1949), җәмәгать эшлеклесе С.Н. Максуди (1875–1945), язучылар З. Бигиев, Г. Камал, А. Шамов һ. б. белем алганнар.

Казан шәһәренең өченче мәхәллә мәчете Иске Татар бистәсенең читендәрәк төзелә башласа да, бу җир бик тиз арада Иске Татар бистәсенең мөһим бер урынына әйләнә. Өченче мәхәлләгә караган җирдә сәүдә, сәнәгать үсә башлый, яңа йортлар төзелә, мәхәллә киңәя. Бу мәхәлләдә 1799 елдан «Апанай» мәдрәсәсе шәкертләре өчен С. Мостафин төзеткән кечерәк кенә агач мәчет эшләп килгән. 1872 елда Мөхәммәдсадыйк Корбангали улы Борнаев киләчәктә Борнай мәчете дип аталачак мәчет салуга рөхсәт ала. Шактый көчле мәхәллә булса да, мәчет каршында озак вакытлар мәктәп тә, мәдрәсә дә булмый [6, кгз. 27–28]. 1913 елда мәхәллә мәктәп өчен халык мәктәпләре директорының рәсми рөхсәтен ала. Мәктәп мәчетнең 5 бүлмәсендә урнаша. Җәдидчелек чорында барлыкка килгән уку йорты буларак, Борнай мәчете каршындагы мәктәпнең нигезедә дөньяви фәннәр тора. Шәкертләр дин гыйлеме белән бергә рус телен дә өйрәнгәннәр, ана теле нигезләрен, арифметиканы да үзләштергәннәр. Мөгаллим вазыйфаларын Тау ягы кешесе Дүртенче мәчет каршындагы мәдрәсәне тәмамлаган Җәгъфәрев башкара. XX йөз башында биредә 50 дән артык шәкерт белем ала.

Казан шәһәренең ярлы катламы яшәгән дүртенче мәхәлләсе – Зәңгәр мәчет каршында ачылган мәдрәсә XIX йөз ахыры – XX йөз башында Казан шәһәренең иң атаклы уку йортына әйләнә. 1825 елда ачылган бу мәдрәсә тарихта төрле исем белән билгеле. Каргалы мәдрәсәсен тәмамлап Казанга килгән Габденнасыйр Рахманкул улы әлеге мәхәллә имамы итеп билгеләнгәч, мәчет каршында дини мәктәп ачып җибәрә, соңрак Казан сәүдәгәрләре Йосыф һәм Корбангали Арсаевлар мәдрәсә өчен аерым бина төзеп бирәләр. Бу чорда әлеге уку йорты «Арсаевлар мәдрәсәсе» буларак билгеле була. XIX йөз ахыры – XX йөз башында мәдрәсәнең матди ягын кайгырткан Мөстәкыймовлар нәселе исеме белән «Мөстәкыймовлар мәдрәсәсе», аннан мәдрәсәне матди яктан тоткан Айтугановлар исеме белән аталып йөри. Айтугановлар чорында мәдрәсә өчен яңа бина эшләнә. Мәдрәсәнең фәнни әдәбиятта кулланыла торган «Халидия» исеме монда озак еллар укыткан, мәдрәсәне җитәкләгән имамнар нәселе белән бәйле. Чыгышлары белән Тәтеш өязеннән булган Халитов нәселе кешеләре октябрь инкыйлабына кадәр Зәңгәр мәчеттә имам, «Халидия» мәдрәсәсендә мөгаллим булалар.

Җәдидчелек чорында мәдрәсәләрнең күбесе яңача укуга күчкән вакытта да «Халидия» үзенең традиционлыгына тугры калырга тырыша, монда уку программасының нигезен дини предметлар тәшкил итә. XX гасыр башына кадәр мәдрәсәгә рус телен кертмәгәннәр, рус телендә укуны мәҗбүр итеп куймаганнар. Бу мәдрәсәнең шәкертләре, нигездә, Тау ягы балалары була, бу – имам, мөдәррисләренең чыгышы шул тарафтан булу белән дә бәйледер бәлки. XIX гасырның 70 нче елларында биредә укучы шәкертләр

60 тирәсе булса [1, кгз. 45–46 б.], XX гасыр башына 150 шәкерт белем ала [22, кгз. 2.], октябрь инкыйлабы якынлашкан елларда бу сан бераз кими, 1916 ел мәгълүматы буенча, бу мәдрәсәдә 64 ир бала укый [7, кгз. 1–8].

Бу уку йортын тәмамлаган шәхесләрдән галим Газиз Гобәйдуллин, шагыйрь Г. Сөнгати, драматург Г. Камалны атарга кирәк.

Иске Татар бистәсенең бишенче мәхәлләсе мөселманнар яши торган иң зур өлеше була. XIX йөзнең 80 нче елларында биредә 83 йортта 500 ир-ат, 610 хатын-кыз гомер иткән [4, кгз. 370]. Бу мәхәллә сату-алу үзәкләренең берсе дә була, тора-бара бу мәхәллә әгъзалары арасынан заманының маллы эшкуарлары үсеп чыга. Бишенче мәхәллә мөселманнар арасындагы мөһимлеге ягыннан Беренче («Мәрҗани») һәм Икенче («Апанай») мәхәлләләре дәрәҗәсендә торган мәхәллә була. Имам М. Сәгыйтовнең мәчет каршындагы дини уку йортына конкурент буларак Бохарада дини белем алып кайткан улы – Галимҗан Галиев (Баруди) өчен атасы Мөхәммәтҗан Галиев промышленник Сәйдәшев матди ярдәме белән таштан кечкенә генә бина салып бирә. Шул бинада Г. Баруди шәкертләр җыеп укыта башлый. Яңа заманча рухтагы, киләчәктә «Мөхәммәдия» дип аталачак мәдрәсә эшен шулай башлап җибәрә. Бишенче мәхәлләдә урнашкан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ислам дөньясында атаклы, дәрәҗәле уку йорты булып җитешә. Татар яшьләре арасында барган заманча үзгәрешләр, уку-укытудагы реформа идеяләре нәкъ шушы уку йортында, шушы мәдрәсә шәкертәләре тарафыннан тудырыла. Мәдрәсәдә сәяси, мәдәни ирекле фикерле яшьләр тәрбияләнә. XX йөз башында бу мәдрәсәдә 500 шәкерт белем ала, аларга 20 мөгаллим дәрес бирә. XX йөз башында Бишенче (Галиев) мәхәлләсе казанышлары ягыннан иң алдынгы, башкалардан аерылып тора торган мәхәллә була. Беренчедән, монда эшләп торучы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең авторитеты зур булса, икенчедән, дини китаплар, дәреслекләр чыгаручы нәшриятләр – «Милләт», «Бертуган Кәримевләр» басмаханәләре эшләп килә, өченчедән, монда татар дөньясында беренчеләрдән булып оешкан, хәтта ки бердәнбер татар китапханәсе – «Көтепханаи исламия» дә биредә урнаша.

Казанның алтынчы мәхәлләсе Иске Татар бистәсенең сәнәгать районы була. Мондагы сабын кайнату заводларында эшләгән мөселманнар өчен беренче чорда манарасыз гына беркатлы агач мәчет хезмәт күрсәтә. Промышленник Әҗемевлар акчасына 1887 елда мәчет таштан манаралы итеп салына. Бу мәхәлләнең мәдрәсәсе тарихы бу мәчеттә хезмәт иткән Габделгаффаровлар нәселе белән бәйле. Имам, мөдәррисләре исеме белән аталган «Гаффария» мәдрәсәсе, зур булмаса да, дини белем белән бергә әхлакый тәрбия бирү белән дә аерылып тора һәм татар җәмәгатьчелеге арасында данлыклы була. 1905 елгы мәгълүматлар буенча, мәдрәсәдә 110 шәкерт белем ала, шуның 45 е мәдрәсәдә яшәп укый. 40 шәкерт Казан шәкертләре булса, 70 шәкерт «Гаффария»дә белем алу өчен чит җирләрдән килгән [22, кгз. 42]. Бу мәдрәсә 1871 елда сәүдәгәр М.М. Әҗемев төзеткән беркатлы таш бинада урнаша. Мәдрәсә каршында мәктәп тә эшләп килә [19, кгз. 1–7].

XX йөз башында бу уку йортларында дин гыйлеменнән Хисаметдин Габделгаффаров, Мирзагабидулла Габделгаффаровлар белем бирә. Укыту процессына шушы мәдрәсәдә укыган шәкертләр Зиһанша Нәҗметдинов, Баһаветдин Зарифов, Шәмзаман Шәмҗиһанов, Габделхәйхан Сафабутдинов, Сәмигулла Хәсәневләр дә ярдәм иткән [19, кгз. 1–7].

Җиденче мәхәллә мәчете Печән базары, башка сату-алу лавкалары урнашкан җирдә 1848 елларда төзелеп бетә [5, кгз. 1–14]. Юнысовлар салдырган бу мәчет халык телендә «Печән базары мәчете» буларак билгеле. Мәхәллә мәчете каршында мәктәп эшли башлый. Алдынгы карашлары белән аерылып торган Г. Апанаев үз акчасына Евангелистлар урамындагы үз йортында мәдрәсә оештырып җибәрә. 1906 елгы мәгълүмат буенча мәдрәсәдә 64 шәкерт укый [5, кгз. 1–14]. Яңача укыткан бу мәдрәсә татар яшьләре арасында популяр уку йорты була. Мөдәррис Салиховның дини белем бирүенә, заманга яраклы үзгәреш кертергә теләмәвенә җавап итеп Әхмәдһади һәм Садри Максудилар, Г. Исхакый «Апанай» мәдрәсәсеннән бу уку йортына күчәләр. 1908 елда Габдулла Апанаев укыту эшеннән читләштерелгәннән соң, Мөхәммәдтаиб Алтынбаев Габдулла Апанаев керткән яңалыкларны тыя башлый, бу чорда уку йорты гади дини мәдрәсә рәвешен ала [19, кгз. 1–7]. «Үтәмешев» мәдрәсәсе дип тә аталган бу уку йортында 1913 елда 65 шәкерт, ә мәдрәсә каршындагы мәктәбенә 35 шәкерт белем ала. Укыту аваз методы белән алып барыла, әмма конкрет укыту программасы булмый. Мәдрәсәдә уку вакыты 10 ел, мәктәпнең уку курсы 4 елга исәпләнгән була. «Үтәмешевләр» мәдрәсәсе аерым хәйриячеләр, мәхәллә кешеләре акчасына һәм шулай ук мәдрәсә урнашкан йортта лавкаларны арендагы бирү акчасына тотылган [20, кгз. 217–218 б].

Казан шәһәренең XIX йөз ахыры – XX йөз башындагы атаклы уку йортларының берсе булган «Госмания» мәдрәсәсе шәһәрнең сигезенче мәхәллә мәчете белән бер чорда төзелә. Мәчет төзергә рөхсәт алып, үз акчасына мәчет кенә түгел, ә мәчет тирәсендә тулы бер комплекс төзергә ният иткән Җиһанша Госманов җитәкчелегендә башлана. Мәчетне 1868 елда төзетеп бетергән Җиһанша Госманов 1870 елда дөнья куйганнан соң, аның эшен улы дәвам итә. «Госмания» мәдрәсәсе 1871 елда төзелеп бетә. Мәдрәсә «Госмания» исеме белән билгеле булса, Җиһанша Госманов төзеткән мәчет аның эшен дәвам иткән улы – Солтангабделгазиз (Солтан) Госманов исеме белән «Солтан» мәчете буларак яши. Солтан Госманов, әтисе кебек үк, эшеннән зур табыш алмаса да, булган малыннан мәчетне, «Госмания» мәдрәсәсен тотарга акчасын кызганмый. Шулай да 1892 елда «Госмания» мәдрәсен тотуга, аны тәртипкә китерүгә Солтан Госманов тиешле дәрәҗәдә игътибар бирми, мәдрәсәгә тиешле акча тулысынча аның ихтыяҗына тотылмый дип мөдәррис Гарифулла Салихов инспектор исеменә шикаять бирә [15, кгз. 45–46 б].

Укыту ягыннан, программасы белән шул заманның башка мәдрәсәләреннән әллә ни аерылмый. Монда да шул ук әлифба, хәдис, ислам дине нигезләре, Коръән өйрәтелгән. Дөньяви предметлар буенча дәресләр бул-

маса дә, уку әсбаблары булып яңача фикер йөртүче мөгаллимнәр авторлыгындагы китаплар, дәреслекләр куллану уку процессын камилләштергән. Мәдрәсәдә кулланылган 35 дәреслек арасында Г. Баруди, Ш. Әхмәрев, Г. Зәбири, Ә. Максуди һ.б. дәреслекләре булу шул хакта сөйли. Мәдрәсәдә уку-укыту куелышы белән Казанның дәрәҗәле уку йорты булганлыктан, монда укырга теләүче шәкертләр күп була. 1905 елгы рәсми мәгълүмат буенча шәкертләр саны 102 дип күрсәтелсә дә [22, кгз. 2], чынлыкта исә «Госмания»дә 300 гә якын шәкерт белем алган [16, кгз. 99–100]. Гадәттә мәдрәсә җитәкчеләре шәкертләрнең чынлыкта булган санын тикшерүче органнардан яшерә торган була. Рәсми булмаган саннар ягыннан караганда, «Госмания» Галиевләр мәдрәсәсеннән («Мөхәммәдия») бераз гына калышкан, ул шәкертләрнең рәсми саны ягыннан «Мөхәммәдия», «Апанай» мәдрәсәсеннән кала өченче урында торган мәдрәсә.

Бу уку йорты үзенең рус классы белән дә аерылып торган, рус телен өйрәнергә теләп «Апанай», Галиевләр мәдрсәсеннә укырга кереп тә «Госмания» мәдрәсәсенә күчкән шәкертләр була [18, кгз. 102–103 б].

Дин гыйлеме укытучысы Гарифулла Салихов мәдрәсәгә рус телен укытуны кертергә ашкынып тормаса да, заман таләбен дә искә алып, мәдрәсә каршында рус класслары барлыкка килә. Мәдрәсәдә рус телен укыта башлауга шәкертләр дә куркып карыйлар, бирегә рус теле укытучысы буларак килгән А. Саттаров [11, кгз. 4–5] истәлекләренә караганда, беренче чорда шәкертләр рус теле дәресенә йөрү түгел, ә рус теле укытучысы белән аралашырга да теләмәгәннәр. Саттаров беренче дәресләрен рус классы бинасында түгел, ә мәдрәсә бүлмәләрендә үткәрергә мәҗбүр була. Әкренләп шәкертләрнең ышанычын яулагач кына, рус классында укучылар барлыкка килә, 15 укучы җыя алалар. Саттаров башка уку йортына күчкәннәннән соң «Госмания»дә рус телен укыту йомшый башлый, килгән укытучылар шәкертләрнең начар мөнәсәбәтләрен күтәрә алмый китә торалар. Мәдрәсә җитәкчеләре дә моннан файдаланып, рус теле укытучысына хезмәт хакы түләми башлыйлар. 1881 елда Ш. Таһиров укытучы итеп билгеләнгәннән соң, хәл уңай якка үзгәрә башласа да, 1882 елның ахырына шәкертләр арасында татар-рус мәктәпләренә каршы көрәш башлагач, 1883 елда Ш. Таһиров та мәктәптән китеп бара [12, кгз. 25–29]. Күренекле галим-тарихчы Гайнетдин Әхмәревнең бертуган энесе – Шәрәфулла Әхмәрев, үзе дә дәреслекләр авторы булган педагог, мондагы рус телен укытуны югары дәрәҗәгә күтәрә ала. 1897 елда «Госмания» мәдрәсәсенең рус классларында 19 шәкерт исәпләнә [16, кгз. 99–100].

Иске Татар бистәсенең ике мәчете: Казаковлар мәчете һәм иске Татар зиратындагы мәчетләрнең язмышы гомерле булмый, аяныч тәмамлана. Уникенче мәхәллә мәчете буларак төзелгән Казаковлар тарафыннан салдырылган бу мәчетнең бинасы сакланмаган. 1898 елда Казан шәһәренең I гильдияле сәүдәгәре Сөләйман Мөхммәтҗан улы Аитов Казанның Евангелистлар урамындагы йортын утары белән Казаков мәчетенә мәдрәсә ачу өчен хәйрия итә. Шарт буенча монда мәхәлләнең бар ир балалары да 16

яшенә кадәр рус телен өйрәнергә тиеш, рус класслары чыгымнары мәхәллә исәбеннән тотылырга тиеш була [17, кгз. 176]. Мәдрәсә попечителе итеп Исмәгыйль Исхаков, җитәкчесе итеп Хәбибулла Госманов билгеләнә. 1905 елда Казаковлар мәдрәсәсендә 49 шәкерт белем алган, шуларның 26 сы мәдрәсәдә яшәп укыган [22, кгз. 42]. Дин гыйлеме буенча мөгаллимнәр – Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаган Хәбибулла һәм Габдулла Госмановлар [19, кгз. 1–7]. Укытуның махсус программасы булмый, мәдрәсәдә ислам дине нигезләре, татар һәм гарәп теле грамматикасы өйрәтелгән. Шулай да укыту процессында реформатор Г. Баруди дәресләкләрен куллану укытуга заманча үзгәрешләр кертелүе турында сөйли. 1912/13 уку елында Казаковлар мәдрәсәсендә 15 шәкерт, ә мәдрәсә каршындангы мәктәптә 30 шәкерт белем алган [20, кгз. 212–213 б].

Иске Татар бистәсенең Иске Татар зираты урынында салынган мәчете унҗиденче номерлы мәхәллә мәчете буларак билгеле. Кызганыч, аның да бинасы сакланмаган. 1906 елда төзелеп беткән мәдрәсәгә имам итеп «Халидия» мәдрәсәсен тәмамлаган Мөбарәкҗан Гарифулла улы Мансуров билгеләнә. Прогрессив карашлы имам мәчет каршында мәктәп ачып җибәрә, аңа укытуда «Халидия» мәдрәсәсен тәмамлаган Исхак Мөштәриев ярдәм итә. 1911 елда ачылган бу мәктәптә 120 бала белем ала. Аларга төрки, гарәп теле, дини гыйлемнәр, хәдис, тәфсир, ислам тарихы, матур язу кагыйдәләре, география, арифметика өйрәтелә, хәтта сату-алуга өйрәтә торган курс та була.

Татарларның үзләре тарафыннан оештырылып, үзләре яшәткән уку йортлары, рухи тормышның үзәге булган мәчетләр эшчәнлеге – гомумән, тарих өчен уникаль бер күренеш. Әлбәттә, мәгълүм шартларда мондый системаны булдыру мөлкәтле катлам катнашыннан башка була алмас иде. Белем белән мөлкәт берләшә алу – шулай ук татар мәгарифе үсешенең үзенчәлекле бер билгесе. Татар мәгарифе кыска гына вакыт арасында туып, зур тизлек белән үсеш алуга ирешә. Кыска гына вакыт эчендә бу уку йортлары кадими уку йортларыннан заман таләпләрен исәпкә алып, заманга яраклы шәкертләр тәрбия итә алырлык уку йортлары – җәдиди мәдрәсәләр булып житешәләр. Казан шәһәре – татар мәгарифе үзәге дибез икән, беренче чиратта, Казанның Иске бистәсе күз алдына килә. Мәгарифнең башлангычы бистәдән булуга тарихи вакыйгалар сәбәп. Әлбәттә, соңрак Казан шәһәренең башка җирләрендә дә мәчетләр ачыла, мәчетләр каршында мәктәпләр эшли башлый. Шулай булса да, башлангычы татарларның белем һәм мәдәни үзәге булган Татар бистәсеннән килә. Кызганыч, әлегә кадәр бу тема фәнни әдәбиятта комплекслы рәвештә тиешенчә яктыртылу тапмаган. Моның үз сәбәпләре бар: бу теманы ныклап өйрәнү мөмкинлеге бирә алырлык язма чыганаклар аз сакланып калган. Булган кадәр материалдан, Иске Татар бистәсендә татар мәгарифенең туу һәм үсеше, андагы уку йортлары эшчәнлеге хакында мәгълүмат бирергә тырышылды. Әмма бу тема алга таба да тикшерүне таләп итә.

1917 елгы инкыйлабка кадәрге чорда татар мәгарифе үсеше үзенең югары ноктасына җитә. Татарның үз җәмәгатьчелеге тарафыннан оештырылып халыкка хезмәт иткән уку йортлары, ислам дөньясында танылу алган мәдрәсәләре – татар халкының тиңе булмаган зур казанышы.

## ӘДӘБИЯТ

1. Государственный архив Республики Татарстан [ГА РТ]. Ф. 1. Оп. 3. Д. 3538.
2. ГА РТ. Ф. 1. Оп. 4. Д. 5482.
3. ГА РТ. Ф. 1. Оп. 6. Д. 949.
4. ГА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 2598.
5. ГА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 7317.
6. ГА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 8961.
7. ГА РТ. Ф. 2. Оп. 2. Д. 9767.
8. ГА РТ. Ф. 92. Оп. 1. Д. 6889.
9. ГА РТ. Ф. 92. Оп. 1. Д. 19380.
10. ГА РТ. Ф. 92. Оп. 1. Д. 11513.
11. ГА РТ. Ф. 92. Оп. 1. Д. 16922.
12. ГА РТ. Ф. 92. Оп. 1. Д. 17454.
13. ГА РТ. Ф. 92. Оп. 1. Д. 19380.
14. ГА РТ. Ф. 92. Оп. 2. Д. 9607.
15. ГА РТ. Ф. 160. Оп. 1. Д. 698.
16. ГА РТ. Ф. 160. Оп. 1. Д. 815.
17. ГА РТ. Ф. 160. Оп. 1. Д. 847.
18. ГА РТ. Ф. 160. Оп. 1. Д. 1093.
19. ГА РТ. Ф. 160. Оп. 1. Д. 1441.
20. ГА РТ. Ф. 160. оп. 1. Д. 1576.
21. ГА РТ. Ф. 977. Оп. Совет. Д. 318.
22. ГА РТ. Ф. 1118. Оп. 1. Д. 32.
23. Медресе Казанской губернии второй трети XIX – начала XX в.: сборник документов и материалов. Казань: Главное архивное управление при Кабинете Министров Республики Татарстан, 2012. 319 с.
24. Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 236 б.
25. Мәрҗани Ш.Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 414 б.
26. Салихов Р. Р., Хайрутдинов Р.Р. Исторические мечети Казани. Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. 191 с.
27. Фукс К. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1844. 131 с.

**Автор турында белешмә:** Сәлахова Эльмира Кадим кызы – тарих фәннәре кандидаты, Татарстан республикасы халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, Татарстан республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин урамы, 7А, Казан, Россия Федерациясе); ilsalah@mail.ru

# СТАРО-ТАТАРСКАЯ СЛОБОДА Г. КАЗАНИ – ЦЕНТР ТАТАРСКОГО ПРОСВЕЩЕНИЯ XIX – НАЧАЛА XX ВВ. (ИСТОРИЧЕСКИЙ ОБЗОР УЧЕБНЫХ ЗАВЕДЕНИЙ)

***Э.К. Салахова***

*Институт истории им. Ш.Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*ilsalah@mail.ru*

Старо-Татарская слобода является историческим центром современной Казани, где сохранились архитектурные памятники, хранящие многовековую историю татарского народа. Образование слободы связано с драматическими событиями в истории народа.

После падения Казанского ханства в 1552 г. жизнь татарского общества перемещается в слободу, расположенную за озером Кабан. К концу XVI в. Старо-Татарская слобода становится своеобразным мусульманским пригородом города Казани. Первая мечеть и первые мусульманские учебные заведения открываются именно на этой территории. Старо-Татарская слобода на протяжении нескольких столетий была образовательным и культурным центром татар. Изучение духовной жизни Старо-Татарской слободы является важной научной темой для исследователей. Жители этой слободы смогли не только сохранить, но и развить городскую культуру татарского населения Казани. Здесь они строили мечети, открывали мектебы и медресе, создавали материальные условия их существования.

Новизной исследования является комплексное рассмотрение становления и развития татарского просвещения в отдельно взятой в Старо-Татарской слободе г. Казани в XIX – начале XX вв.

Цель публикации – изучить и проанализировать историю создания и развития учебных заведений: мектебов и медресе, показать их значимость в духовной жизни татаро-мусульманского сообщества. Для достижения указанной цели был поставлен ряд задач. Известно, что история образовательных заведений у татар тесно связана с историей становления мечетей. В подавляющем большинстве мектебы открывались при мечетях. Медресе как средние и высшие ступени обучения шакирдов, хотя формально и считались самостоятельными учреждениями, тем не менее, их создание и развитие были напрямую связаны с религиозными учреждениями. Учебный процесс обеспечивали духовные лица мечетей – имамы-хатибы. Поэтому, по нашему убеждению, история становления учебных заведений должна изучаться во взаимосвязи с историей мечетей.

В исследовании рассматриваются 10 махалля и мечетей, расположенных на территории Старо-Татарской слободы. Автор дает информацию о мечети определенной махалли, там же раскрывает историю создания и развития учебного заведения, относящегося к данной махалле. Также автор рассматривает этапы перехода от кадимистского к джадидистскому обучению в медресе слободы.

В статьи показаны периоды культурного и образовательного освоения Старо-Татарской слободы. Первая мечеть, именуемая в настоящее время мечетью

Марджани, стала первым культовым сооружением на территории слободы, не намного отставая, воздвигается Апанаевская мечеть.

На материальной базе мечетей открывались знаменитые учебные заведения, успешно конкурировавшие с другими мусульманскими учебными заведениями Российской империи. Деятельность медресе «Марджани», «Апанаевской медресе» служат тому подтверждением. В статье дается развернутая информация о медресе «Мухаммадия», «Халидия», «Гаффария», медресе «Утямышевых», «Гусмания» и др. Следует оговориться, что названия некоторых медресе менялось, одно и то же медресе в разные периоды в источниках указано под разными названиями. Это также объясняется автором публикации. Автор на примере крупных медресе показывает методы обучения, их изменения в связи с требованиями времени. Материалы исследования дают возможность представить организацию учебного процесса в мектебах и медресе, проследить динамику числа шакирдов в разные периоды. Так как организация учебного процесса во всех медресе была примерно одинакова, подробное описание учебного процесса в каждом медресе было бы излишним, поэтому автор акцентировал внимание на других фактах. Сохранившиеся архивные источники по медресе «Касымия» позволяют создать полное представление о проблемах внедрения русского языка в медресе и восприятии шакирдов нового предмета. Такая же ситуация с русским языком складывалась и в других медресе.

Медресе и мектебы готовили образованных молодых людей, которые к началу XX в. составляли наиболее активную часть татарской интеллегенции. Они становились видными учеными, писателями, педагогами и деятелями культуры. Автор под текстами о медресе перечисляет и видных выпускников этих мусульманских учебных заведений.

Создание мечетей, медресе, их содержание было бы невозвожным без участия зажиточного слоя татарского общества. Упоминание имен купцов и предпринимателей Юнусовых, Арсаевых, Мустафиных, Азимовых и многих других благотворителей дополняет наше знание по истории развития образования татар.

Исследование основано на архивных документах, а также на научной литературе по данной тематике.

**Ключевые слова:** мечети Старо-Татарской слободы, учебные заведения Старо-Татарской слободы, школы при мечетях, образование у татар, история татарского народа, медресе «Касымия», мечеть Марджани, Апанаевская мечеть, медресе «Мухаммадия», татарские благотворители.

**Для цитирования:** Салахова Э.К. Казанның Иске Татар бистәсе – XIX–XX йөз башында татар мәгарифе үзәге (уку йортларына тарихи күзәтү) // Историческая этнология. 2019. Т. 4, № 2. С. 294–311. DOI: 10.22378/he.2019-4-2.294-311

**Сведения об авторе:** Салахова Эльмира Кадимовна – кандидат исторических наук, старший научный сотрудник отдела историко-культурного наследия народов РТ, Институт истории им. Ш.Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); ilsalah@mail.ru

# OLD TATAR QUARTER OF KAZAN – THE CENTER OF TATAR EDUCATION OF THE19$^{TH}$ –EARLY 20$^{TH}$ CENTURIES (HISTORICAL OVERVIEW OF EDUCATIONAL INSTITUTIONS)

***E.K. Salakhova***

*Sh.Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*ilsalah@mail.ru*

The Old Tatar Quarter is the historical center of modern Kazan, where architectural monuments preserving the centuries-old history of the Tatar people have been preserved. The formation of the settlement is associated with dramatic events in the history of our people. After the fall of the Kazan Khanate in 1552, the life of the Tatar society moved to the settlement, located behind the Kaban lake. By the end of the 16$^{th}$ century. The Old Tatar Quarter becomes a kind of Muslim suburbian area of Kazan. The first mosque and the first Muslim educational institutions were opened in that territory. For several centuries, the Old Tatar Quarter was the educational and cultural center of Tatars. The study of the religious life of the Old Tatar Quarter is an important subject for researchers. Residents of this settlement were able not only to preserve, but also to develop the urban culture of the Tatar population in Kazan. There they built mosques, opened the mektep and madrasas, created material conditions to maintain their existence.

The study is novel in that it is a comprehensive review of the formation and development of the Tatar enlightenment in the separately considered Old Tatar Quarter of Kazan in the the 19$^{th}$ – early 20 $^{th}$ centuries. The purpose of this publication is to study and analyze the history of establishing and developing educational institutions – mektebe and madrasas, to show their significance in the religious life of the Tatar-Muslim community. To achieve this goal, a number of tasks were set. It is a well-known fact that the history of educational institutions among the Tatars is closely connected with the history of mosques formation. A vast majority of schools opened at mosques. Madrasas, as the middle and higher levels of education of shakirds, although formally considered independent institutions, nevertheless, their creation and development is directly related to religious institutions. The educational process was provided by the clerics of mosques – Imam-khatiba. Therefore, from our perspectibe, the history of educational institutions formation should be studied in conjunction with the history of mosques.

The study examines 10 mahallas and mosques located on the territory of the Old Tatar Quarter. When the author provides information about the mosque of a certain mahalla, he also reveals the history of the establishment and development of an educational institution belonging to this mahalla. The author also considers the transition from radimitschi to djadidists method of teaching in madrasas settlement.

*Салахова Э.К.* Казанның Иске Татар бистәсе – XIX–XX йөз башында татар мәгарифе үзәге (уку йортларына тарихи күзәтү)

The article investigates the periods of cultural and educational development of the Old Tatar settlement. The first mosque, now called the Marjani mosque, became the first religious building on the territory of the settlement, not far behind, the Apanaev mosque was built.

Famous educational institutions opened on the facilities of mosques and successfully competed with other educational institutions of the Muslim world in the Russian Empire. The madrasas *of Marjani*, *Apanaev madrasa* are indicative of that. The article also provides detailed information on the madrasa: *Muhammadiya*, *Khalidiya*, *Gaffariya*, *Utyasheva* madrasa , *Guzmaniya*, etc. It should be noted that the names of some madrasas have changed, the same madrasas in different periods are indicated in the sources under different names. It is also explained by the author of the publication. The author on the example of large madrasas shows teaching methods, their changes in connection with the requirements of time. The materials of the study make it possible to present the organization of the educational process in mektebs and madrasas, to trace the dynamics of the growth of the number of shakirds or their decline in different periods. Since organization of the educational process in all madrasas was approximately the same, a detailed description of the educational process in each madrasa would be unnecessary, therefore, the author focused on other significant facts. Archival sources at the madrasa *Casamia* give an opportunity to create a complete view on the problems of implementing the Russian language in the madrasas and the perception of shakerdom a new subject. The same situation with the Russian language developed in other madrasas.

Madrasas and mekteps prepared educated young people, who by the beginning of the 20th century constituted the most active part of the Tatar intelligentsia. They became prominent scholars, writers, teachers, and cultural figures. Moreover, the author under the texts about madrasas lists prominent graduates of these Muslim educational institutions.

The creation of mosques, madrasas, their maintenance would have been impossible without the participation of the wealthy stratum of Tatar society. Mention of the names of merchants and entrepreneurs Yunusov, Arsaev, Mustafin, Asimov and many other benefactors complements our knowledge of the history of education of the Tatars.

The research is based primarily on archival documents, as well as on scientific literature on the given subject.

**Keywords:** mosques of the Old Tatar Quarter, educational institutions of the Old Tatar Quarter, schools attached to mosques, education among Tatars, history of the Tatar people, Madrasa Kasimiya , the Mardjani Mosque, Apanaev Mosque, Madrasa Muhammadiya , Tatar benefactors.

**For citation:** Salakhova E.K. Old Tatar Quarter of Kazan – the center of Tatar education of the 19th – early 20th centuries (historical overview of educational institutions). Istoricheskaya etnologiya – Historical Ethnology, 2019, vol. 4, no. 2, pp. 294–311. DOI: 10.22378/he.2019-4-2.294-311

REFERENCES

1. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 1. Op. 3. D. 3538. (In Russian)
2. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 1. Op. 4. D. 5482. (In Russian)
3. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 1. Op. 6. D. 949. (In Russian)
4. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 2. Op. 2. D. 2598. (In Russian)
5. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 2. Op. 2. D. 7317. (In Russian)
6. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 2. Op. 2. D. 8961. (In Russian)
7. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 2. Op. 2. D. 9767. (In Russian)
8. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 92. Op. 1. D. 6889. (In Russian)
9. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 92. Op. 1. D. 19380. (In Russ).
10. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 92. Op. 1. D. 11513. (In Russian)
11. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 92. Op. 1. D. 16922. (In Russian)
12. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 92. Op. 1. D. 17454. (In Russian)
13. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 92. Op. 1. D. 19380. (In Russian)
14. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 92. Op. 1. D. 9607. (In Russian)
15. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 160. Op. 1. D. 698. (In Russian)
16. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 160. Op. 1. D. 815. (In Russian)
17. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 160. Op. 1. D. 847. (In Russian)
18. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 160. Op. 1. D. 1093. (In Russian)
19. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 160. Op. 1. D. 1441. (In Russian)
20. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 160. Op. 1. D. 1576. (In Russian)
21. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 977. Op. sovet. D. 318. (In Russian)
22. Gosudarstvennyy arkhiv Respubliki Tatarstan [The State Archive of the Republic of Tatarstan]. Fond 1118. Op. 1. D. 32. (In Russian)

23. *Medrese Kazanskoy gubernii vtoroy treti XIX – nachala XX v.: sbornik dokumentov I materialov* [Medrese in the Kazan Province in the second third of the 19th – early 20th centuries. Collection of documents and materials]. Kazan, Main Archive Department at the Republic of Tatarstan Cabinet of Ministers, 2012. (In Russian)

24. *Medresalarda kitap kishtase* [Bookshelves in medrese]. Kazan, Tatar Book Publ. House, 1992. (In Tatar)

25. Marzhani Sh. B. *Mustafadel-akhbar fi akhvali Kazan va Bolgar* [Information about Kazan and Bulgar]. Kazan, 1989. (In Tatar).

26. Sakikhov R.R., Khayrutdinov R.R. *Istoricheskie mecheti Kazani* [Historical mosques of Kazan]. Kazan, Tatar Book Publ. House, 2005.

27. Fuks K. *Kazanskie tatary v statisticheskom i etnohroficheskom otnosheniyakh* [Kazan Tatars in terms of statistics and ethnography]. Kazan, Printing House of Kazan University, 1844, 131 p. (In Russian)

**About the author:** Elmira K. Salakhova is a Candidate of Science (History), Senior Research Fellow, Department of History and Cultural Heritage of the Peoples of Tatarstan, Sh.Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); ilsalah@mail.ru